КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 18 сентябрь г.Казань № 879

Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен;

наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү комиссиясе составын.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин